**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**2022 елның 21 июне** **95 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советының 2018 елның 100 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында "гы 100 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Атабай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында "гы 100 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга

3. Карарның  үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Хәлиловага йөкләргә.

Башлык-Татарстан  Республикас
Лаеш  муниципаль  районы
Атабай авыл  җирлеге Советы рәисе                                         Л.Р.Хәлилова

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Атабай авыл җирлеге Советының
2022 елның 21 июнендәге 95 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Атабай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмә

**1) 1.6 пунктын түбәндәге пункт белән тулыландырырга:**

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре, инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

**2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

Әлеге статьяда каралган гражданнарның җыены, торак пунктта яисә җирлектә яшәүче сайлау хокукына ия булучыларның яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия халыкның яртысыннан күбрәге бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, халык җыены, әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә, этаплап, җыен үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.";

**3) 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча».